ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРСАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул .Центральная, д.5, с. Урсаево,
Заинский район, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная урамы, 5 нче йорт,
Урсай авылы, Зәй районы, 423535

Телефон, факс 2-80-46.
Электронный адрес: Ursaev.zai@tatar.ru, сайт: http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ursaevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№8**

**КАРАР**
**от 26.05.2021 г.**

**"2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасы турында" 2021 елның 26 февралендәге №3 номерлы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге башкарма комит

КАРАР БИРӘ:

1. "2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасы турында" 2021 елның 26 февралендәге №3номерлы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтада:

а) Программа паспортының 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| Программаны финанслау күләмнәре һәм | Финанслау чыганагы | Еллар | | | Гамәлгә ашыру чорында |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| чыганаклары, елларга бүлеп | | | | | барысы |
| | Җирле бюджет | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 3000,00 сум |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм муниципаль бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә мөмкин. | | | | |

б) Программаны ресурслар белән тәэмин итү 6 нчы бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны гамәлгә ашыру җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла. Программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның еллык күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында Совет карары белән раслана.

| Чыганаклар һәм чыгымнарның юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барысы | шул исәптән, елларга бүлеп | | |
| | | 2021 | 2022 | 2023 |
| Җирле бюджет | 3000,00 | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 1000,00 сум |

»;

1.2. 2 нче кушымтада:

2 нче бүлекнең 2.3 бүлекчәсе юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмат буклетлары, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү, авыл җирлегенең рәсми сайтында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа дәүләт ярдәме турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмат белән тәэмин итү | Җирлекнең башкарма комитеты | Җирле бюджет | 2021 - 2023 еллар |

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.А. Гатина**